БУГУЛЬМИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
IV СОЗЫВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
IV ЧАКЫРЫЛЫШ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.03.2025г. г. Бугульма № 4

**УТЫЗ ИКЕНЧЕ СЕССИЯ**

**Бөгелмә шәһәр Советының «Җир салымы турында»2024 елның 13 сентябрендәге 2 нче номерлы XXIX сессиясе карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенең 31 бүлеге нигезендә Бөгелмә шәһәр Советы

Карар кылды:

1. Бөгелмә шәһәр Советының 2024 елның 13 сентябрендәге «җир салымы турында» XXIX сессиясенең 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 өлешнең 1 абзацында «җир кишәрлекләренең кадастр хакыннан чыгып» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2 өлешнең 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Татарстан Республикасы бюджетыннан, Бөгелмә муниципаль районы бюджетыннан һәм Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан финанслана торган бюджет, автоном, казна учреждениеләре файдалануындагы җир кишәрлекләренә карата 0,9 процент";

1.3. 3 өлешнең 12 абзацын төшереп калдырырга;

1.4. 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа пунктлар өстәргә:

«4.1. Календарь ел салым чоры дип танылa. Салым түләүче-оешмалар өчен хисап чоры итеп календарь елның беренче кварталы, икенче һәм өченче кварталы танылa;

4.2. Салым һәм аванс түләүләре салым түләүче - оешмалар тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының 397 статьясындагы 1 пунктында билгеләнгән срокларда түләнергә тиеш.».

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Бөгелмә шәһәре муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Бөгелмә шәһәре мэры урынбасары И. Б. Белова**